Утверждаю

Директор гимназии______ Баклашова О.Н.

«24»августа 2020г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА.

## Кружок

## «Сценическое искусство на татарском языке».

## МБОУ «Гимназии №6» Приволжского района города Казани.

Руководитель кружка: Низамиева Л.Н.

2020-2021 учебный год.

**Казан шәһәре Идел буе районының
муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе
“6 нчы Гимназия”**

**“Манзара” исемендәге театр түгәрәгенең 2020-2021 нче уку елына эш планы.**

**Җитәкчесе: Латыпова Зөлфия Наил кызы.**

## Аңлатма язуы

Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырылды. “Драма” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплады. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.Түгәрәктә  сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп.  Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр дигән фикергә килдем.

Һәр халык үзенә хас булган, гореф-гадәтләргә бай. Соңгы вакытта туган телебезгә, шулай ук борынгыдан килгән йолаларга игътибар бик нык артты, чөнки татар халкының, башка халыклар кебек үк тарихы, үткәне бик бай, йола-бәйрәмнәре һәм уеннары да күп төрле.

Түгәгрәк программасын төзгәндә, укучыларны шушы халык бәйрәмнәре һәм йолалары үрнәгендә тәрбияләү, җыр-биюләрне, такмак-такмазаларны өйрәтү, шулар аша дуслык хисләре тәрбияләү, милли хисләр, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү алгы планга куелды.

Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы  кулланыла.

Театр сәнгатенә караган материаллар, драматурглар, артистлар, театр труппалары турындагы мәгълүматлар, драматургларның әсәрләре программаның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шулай ук спектакльләргә бару, видеофильмнар карау, күренекле артистлар белән очрашулар укучыларның театр сәнгате буенча осталыкларын үстерүдә зур урын алып тора.

**Максатлар:**

1. Укучыларда татар театрына карата кызыксыну уяту.
2. Укучыларга сәхнә серләрен төшендерү.
3. Татар артистлары белән якыннан танышуэ
4. Драматургларның тормыш юлы, иҗаты белән танышу.
5.Укучыларның сөйләм телләрен үстерү өчен шартлар булдыру.
6. Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнү.
7. Киенү, бизәнү әдәпләрен үстерү.

**Бурычлар:**

1. Татар театры тарихын белү;
2. Сәхнәдә тиешле таләпләрне үтәп, тамашачыга җиткерерлек итеп, чыгыш ясый алу;
3. Сөйләм телен үстерү;
4. Татар спектакльләренә бару, видеофильмнар карау
5. Татар драматургларының эшчәнлеген белү;
6. Татар артистларының тормышы белән якыннан танышу

## ^ Календар-тематик план

| № | Тема | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | 2017-2018 нче уку елына түгәрәк эшенең планы белән таныштыру .<br>Театр сәнгате, үзенчәлекләре | 2сәг. |
| 2 | Татар театры үсеше. Татар артистлары | 4 сәг. |
| 3 | Сәхнә әсәрләренең үзенчәлеге | 3 сәг |
| 4 | Сөйләм культурасы, сөйләмнең аңлаешлылыгы | 4 сәг. |
| 5 | Сөйләм үтемле булсын. Сөйләм аһәңле булсын | 3 сәг |
| 6 | Яраткан шигырьне яттан сөйләү | 2 сәг |
| 7 | Мимика, жест, хәрәкәт. Аларның үзенчәлеге | 6 сәг. |
| 8 | Монолог. Үзенчәлеге.Үзеңә охшаган монологны сөйләү. | 4 сәг |
| 9 | Диалог. Бирелгән темага диалог сөйләү | 3 сәг |
| 10 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре | 4 сәг |
| 11 | “Сәйәр” театр фестиваленә әзерләнү<br>Г.Камалның “Беренче театр”әсәрен кабатлау, репетицияләр ясау. | 6 сәг. |
| 12 | Костюмнарны әзерләү. | 3 сәг. |
| 13 | Сөйләм өстендә эш | 2 сәг |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | Аерым образлар өстендә эш | 6 сәг |
| 15 | Җырлар өйрәнү | 2 сәг. |
| 16 | Костюмнар сайлау | 2 сәг. |
| 17 | Интерьер. Сәхнә бизәлеше | 3 сәг. |
| 18 | Әсәрне сәхнәгә кую буенча репетицияләр | 7 сәг. |
| 19 | Әниләр көнендә чыгыш ясау | 2 сәг. |
| 20 | “Третий звонок”республика бәйгесенә әзерләнү | 7 сәг |
| 21 | “Третий звонок” бәйгесендә катнашу. | 3 сәг. |
| 22 | “Хәрәкәт - үзе сәламәтлек” сценариесе белән танышу | 2 сәг. |
| 23 | Рольләр бүлү | 2 сәг. |
| 24 | Сөйләм өстендә эш | 3 сәг. |
| 25 | Костюмнар сайлау | 3 сәг. |
| 26 | Әсәрне сәхнәгә кую буенча репетицияләр, бәйгедә катнашу | 7 сәг. |
| 27 | Яңа елга әзерләнү, катнашу | 5 сәг. |
| 28 | “Планетабыз үз кулыбызда” экологик темага сценарий төзү | 2 сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| 29 | “Табигать үзе дәва” өзек сәхнәләштерү, рольләрне искә төшерү | 4 сәг |
| 30 | “Табигать үзе дәва” , сөйләмгә таләпләр | 3 сәг |
| 31 | “Табигать үзе дәва” , образларны ачу өчен киемнәр | 3 сәг. |
| 32 | Образларны ачу өчен жест, мимика | 5 сәг |
| 33 | “Табигать үзе дәва”, репетиция | 5 сәг |
| 34 | Җырлар өйрәнү | 2 сәг. |
| 35 | Презентация ясау | 2 сәг. |
| 36 | Республика семинарына әзерләнү,катнашу | 7 сәг. |
| 37 | “Ягез әле, егетләр” бәйгесенә әзерләнү һәм катнашу | 4 сәг |
| 38 | “Әниләр көне”нә багышлап сценарий төзү, әзерләү, катнашу | 4 сәг. |
| 39 | Т.Миңнуллинның “Җанкисәккәем” комедиясеннән өзек сәхнәләштерү, әсәр белән танышу. | 3 сәг. |
| 40 | Рольләр бүлү | 3 сәг |
| 41 | Сөйләм өстендә эш | 5 сәг. |
| 42 | Аерым образлар өстендә эш | 8сәг. |
| 43 | Костюмнар сайлау | 5 сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| 44 | Интерьер. Сәхнә бизәлеше | 4 сәг. |
| 45 | Әсәрне сәхнәгә кую буенча репетицияләр | 10 сәг |
| 46 | Укытучылар һәм эти-әниләр алдында чыгыш ясау | 3 сәг |
| 47 | Мәктәптә укучыларга күрсәтү | 2 сәг |
| 48 | Бөек Җиңү бәйрәменә сценарий сайлау, әзерләнү | 4 сәг |
| 49 | Укучылар һәм укытучылар, ветераннар алдында чыгыш ясау | 3 сәг. |
| 50 | Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия тетрына бару, спектакль карау | 4 сәг. |
| 51 | "Гаилә көне"н уздыруга әзерләнү, катнашу | 5 сәг. |
| 52 | "Соңгы кыңгырау" сценариесе белән танышу, әзерләнү, катнашу. | 4 сәг. |
| 53 | "Балаларны яклау көне"ндә катнашу | 3 сәг. |
| 54 | К.Тинчурин исемендәгетеатрда  спектакль карау | 2 сәг. |
| 55 | Еллык эшкә отчет | 1 сәг. |

**Кулланылган әдәбият:**


1. Г.Камал театры артистлары турында
2. Татарский Государственный театр рамы и комедии
3. Рәфкать Бикчәнтәев. Истәлекләр.
4. Октябрьгә кадәрге татар театры
5. Наил Әюпов. Иҗат портретына штрихлар
6. Татар театры. 1906-1926 нче еллар
7. Г Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры
8. Фирдәвес Хәйруллина. Юксыну
9. Пионер сәхнәсе

10.К Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры